Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге составына керүче
Рус Әшнәге авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

30 октябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 30 октябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

Рус Әшнәге авылындагы мәктәп, кыр урамнарын ремонтлау

- Рус Әшнәге авылларында контейнер мәйданчыклары ясау һәм төзекләндерү; ;
- Рус Әшнәге авылы урамнарының машиналар йөрү өлешен (урамнарны чистарту) кышкы карап тоту;
- Рус Әшнәге авылында суүткәргеч ремонтлау;

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 280 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 142 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 142 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге составына керүче Рус Әшнәге авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районы  Рус Әшнәге авыл җирлегенең  Рус Әшнәге авыл торак пунктында  тору урыны буенча  теркәлгән  балигъ  булган  һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре)  400 сум күләмендә үзара салым  акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны  җирле әһәмияттәге  мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

Рус Әшнәге авылындагы мәктәп, кыр урамнарын ремонтлау

- Рус Әшнәге авылларында контейнер мәйданчыклары ясау һәм төзекләндерү; ;

- Рус Әшнәге авылы урамнарының машиналар йөрү өлешен (урамнарны чистарту) кышкы карап тоту;

- Рус Әшнәге авылында суүткәргеч ремонтлау;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат  стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге   авылы, Мәктәп урамы, 9а йорты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ХаҗиевХ.В.

Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы Хаҗиев В.Х.